БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«30» 04 2026 ел

**КАРАР**
№ 172

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы штабы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 январендагы 7 номерлы карарына таянып, Балтач районы прокуратурасының 2026 елның 30 мартындагы 02-08-01-2026/Прдп142-26-20920011 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 272 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктның 2.2.1 пунктчасындагы 14 абзацында:

1.1.1. «халык өчен хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.2. «оборона һәм» сүзләрен «оборона, кирәкле көчләрне җиһазлау һәм әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.2 пунктының 2.2.1 пунктчасындагы 16 абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «хәвеф-хәтәрләр килеп чыгу нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.2 пунктының 2.2.1 пунктчасындагы 25 абзацта «хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «хәвеф-хәтәрләр килеп чыгу» сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. 1 бүлектәге 12 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы өлкәсендәге таләпләр - гражданнар оборонасы белән идарә итүнең техник системаларын, сыену урыннарын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын төзү, эксплуатацияләү, халыкка хәбәр итү системаларын, гражданнар оборонасының башка махсус техникасын һәм

мөлкәтен куллануга даими әзерлек халәтендә тоту, халыкны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү, халыкны эвакуацияләүне оештыру, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау һәм саклау өчен әзерләүнең махсус шартлары (кагыйдәләре, тәртибе) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов